| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2018 Казан ш. № 10-130/кс

"ТүбәнКамаНефтехим" гавами акционер җәмгыяте өчен 2019 - 2021 елларга техник суга (химик юл белән чистартылган) һәм агып төшә торган суларны чистартуга (механик) тарифлар билгеләү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "ТүбәнКамаНефтехим" гавами акционер җәмгыяте өчен техник суга (химик юл белән чистартылган) һәм агып төшә торган суларны чистартуга (механик) тарифларны әлеге карарга 1 нче кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "ТүбәнКамаНефтехим" гавами акционер җәмгыяте өчен 2019 - 2021 елларга техник суга (химик юл белән чистартылган) һәм агып төшә торган суларны чистартуга (механик) тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрларын әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "ТүбәнКамаНефтехим" гавами акционер җәмгыятенә һәркем өчен ачык

булырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча ачарга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 7 декабрендәге 10-130/кс
номерлы карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "ТүбәнКамаНефтехим" гавами акционер җәмгыяте өчен 2019 - 2021 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, техник суга (химик юл белән чистартылган) һәм агып төшә торган суларны чистартуга (механик) тарифлар

| т/б № | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Техник (химик юл белән чистартылган) суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | | Агып төшә торган суларны чистартуга (механик) тариф, (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2021 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2021 ел | |
| | | 01.01.2019 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | 2021 елның 1 гыйнварыннан алып 2021 елның 30 июненә кадәр | 2021 елның 1 июленнән алып 2021 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | 2021 елның 1 гыйнварыннан алып 2021 елның 30 июненә кадәр | 2021 елның 1 июленнән алып 2021 елның 31 декабренә кадәр |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | | | | | | |
| 1 | "ТүбәнКамаНефтехим" гавами акционер җәмгыяте (күрсәтелгән тарифларларда НДС исәпкә алынмаган) | 44,15 | 46,74 | 46,52 | 46,52 | 46,52 | 49,26 | 4,77 | 5,00 | 4,98 | 4,98 | 4,98 | 5,21 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 7 декабрендәге 10-130/кс
номерлы карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "ТүбәнКамаНефтехим" гавами акционер җәмгыяте өчен 2019 - 2021 елларга техник суга (химик юл белән чистартылган) һәм агып төшә торган суларны чистартуга (механик) тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме, тариф төре | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | "ТүбәнКамаНефтехим" гавами акционер җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Техник су (химик юл белән чистартылган) | 2019 | 49 065,23 | 1 | - | - | 0,6 |
| | | 2020 | 50 226,11 | 1 | - | - | 0,6 |
| | | 2021 | 51 712,80 | 1 | - | - | 0,6 |
| 1.2 | Агып төшә торган суларны чистарту (механик) | 2019 | 677,34 | 1 | - | - | 0,41 |
| | | 2020 | 693,36 | 1 | - | - | 0,41 |
| | | 2021 | 713,88 | 1 | - | - | 0,41 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге